ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.07.2026 с.Старое Дрожжаное №309

Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм гамәлдәге муниципаль норматив актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 декабрендәге 615 номерлы карары белән расланган өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, **3.6 өлешенең 3.6.3 пунктын** түбәндәге эчтәлекле **3.6.3.4 пунктчасы** белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«3.6.3.4. Балигъ булмаганга карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче балигъ булмаганның законлы вәкиле алганда, балигъ булмаганга карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаганның законлы вәкиле булган мөрәҗәгать итүче дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганның балигъ булмаганга карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен

алуга вәкаләтле башка законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләрне күрсәтә.

Балигъ булмаганга карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазьдәге документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр мөрәҗәгать итүче дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганга карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә күрсәтелергә мөмкин түгел.

2. Документ рәвешендә кәгазь чыганакта рәсмиләштерелгән балигъ булмаган яшькә карата дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен бирү тәртибе, шул исәптән аларны бирү ысуллары һәм сроклары, мөрәҗәгать итүче балигъ булмаган затның законлы вәкиленә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен билгели торган норматив хокукый актлар белән, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 3 өлешендә каралган таләпләрне исәпкә алып билгеләнә.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Җитәкчесе: Р.И. Мөхәммәтҗанов